КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 10 гыйнвар г.Казань № 4

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина территориясендә, Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм аларның туклану чыгымнарын каплау турында» 2022 ел, 30 апрель, 406 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина территориясендә, Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм аларның туклану чыгымнарын каплау турында» 2022 ел, 30 апрель, 406 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 август, 883 нче; 2023 ел, 21 гыйнвар, 30 нчы; 2023 ел, 12 август, 973 нче; 2024 ел, 6 май, 304 нче, 2024 ел, 11 ноябрь, 983 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктның икенче абзацында татар текстында «оешмалар» сүзеннән соң «, индивидуаль эшкуарлар» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә Украина территориясендә, шулай ук реакция бирүнең максималь һәм

уртача дәрәҗәләре кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә яшәүче, торак урыннарын мәҗбүри калдырып киткән Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктлары исемлеге таблицасының 3 нче графасы исемендә «аның базасында» сүзләрен «аның базасында хосусый эшкуар» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин